ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　КАРАР

03.08.2020 ел　　　　Баулы шәһәре　　　　№153

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 19 апрелендәге 117 номерлы карары белән расланган Шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасында булган белешмәләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү турында» 2020 елның 13 мартындагы 279 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 19 апрелендәге 117 номерлы карары белән расланган Шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасында булган белешмәләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 «Гомуми нигезләмәләр» бүлегендә:

1.4 пунктта сигезенче абзацны төшереп калдырырга;

«Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» 2нче бүлегендә:

2.10 пунктта өченче баганада «ПРФ 363нче карарының 14 п.п., 363нче карарның 2 п.п.» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 13 мартындагы 279 карары нигезендә «Шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү турында» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров